Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXIII-1**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 4 сентябре

2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына физик затлар керемнәренә салымнан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына бүлеп бирүләрнең өстәмә нормативы белән муниципаль районның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияне алыштыруны килештерү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 138 маддәсендәге 5 пункты, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.2 маддәсендәге 5 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына физик затлар керемнәренә салымнан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына бүлеп бирүләрнең өстәмә нормативы белән муниципаль районның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияне алыштыруны килештерергә.

2.Әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрергә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Бу карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советы рәисе урынбасары И.Г. Ибраһимов